КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 декабрь г.Казань № 1225

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июль, 511 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 936 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 363 нче; 2017 ел, 16 август, 584 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2018 ел, 25 июнь, 512 нче; 2019 ел, 22 май, 428 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1116 нчы; 2020 ел, 6 апрель, 259 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче; 2021 ел, 12 апрель, 241 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 839 нчы; 2023 ел, 20 июль, 869 нчы; 2023 ел, 29 ноябрь, 1533 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

проект офисы составыннан А.Х.Газизовны, А.Ю.Егоровны, М.Д.Фәйзрахмановны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

проект офисы составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделхаков Рөстәм Рифгать улын | Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директорын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Аюкасов Рөстәм Анатольевичны | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасарын – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директорын |
| Баклашов Антон Николаевичны | «Опора России» бөтенроссия иҗтимагый кече һәм урта эшмәкәрлек оешмасының Татарстан республика бүлеге рәисен (килешү буенча) |
| Насыртдинов Олег Рәшит улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын |
| Начвин Илья Сергеевичны | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын; |

Ренат Вагыйзь улы Гайнетдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия төзү турында» 2018 ел, 12 сентябрь, 770 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 август, 638 нче; 2019 ел, 26 октябрь, 963 нче; 2020 ел, 6 апрель, 259 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче; 2021 ел, 12 апрель, 241 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1190 нчы; 2022 ел, 18 август, 857 нче; 2023 ел, 6 апрель, 424 нче; 2023 ел, 19 июль, 865 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара региональ комиссия составыннан А.Х.Газизовны, М.М.Миңнуллинны, Р.Н.Садыйковны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

Ведомствоара региональ комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын |
| Баклашов Антон Николаевичны | «Опора России» бөтенроссия иҗтимагый кече һәм урта эшмәкәрлек оешмасының Татарстан республика бүлеге рәисен (килешү буенча) |
| Кадыйров Азат Рифгать улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын |

| | |
|---|---|
| Начвин Илья Сергеевичны | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын. |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советын төзү турында» 2022 ел, 15 декабрь, 1343 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 ноябрь, 1407 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Координация советы составыннан А.Ю.Егоровны, М.Н.Садыйковны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын |
| Габделхаков Рөстәм Рифгать улын | Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директорын (килешү буенча) |
| Начвин Илья Сергеевичны | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин